**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 елның «25» августыннан № 425

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2013 елның 25 сентябрендәге 406 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында»**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына мохтаҗлык критерийларын адреслылык һәм куллану принцибын үтәү бурычыннан чыгып социаль ярдәм чараларын күрсәтүне исәпкә алу һәм камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 29 декабрендәге 388-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2017 елның 17 февралендәге 181 номерлы РФ хөкүмәте карары нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2013 елның 25 сентябрендәге 406 нчы карарын түбәндәге эчтәлекле пункт белән тулыландырырга:

- «7. Яңа Чишмә муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларына түләүсез туклануны оештыру буенча социаль ярдәм чаралары турында мәгълүмат Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән

тәртиптә һәм күләмдә Социаль тәэминатның бердәм дәүләт мәгълүмат системасыннан һәм, билгеләгән форматларга туры китереп, Социаль тәэминатның бердәм дәүләт мәгълүмат системасы операторы аша алынырга мөмкин».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә (бастырып чыгарырга).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Р.Р. Фасахов**